СОВЕТ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

10.04.2026 г. Заинск № 35

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында**

Норматив хокукый актларны законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

- «Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 14 ноябрендәге 416 номерлы, шулай ук «Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру турында нигезләмә;
- «Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 14 октябрендәге 416 номерлы Зәй муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында, шулай ук «Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында;
- «Цифрлы финанс активлары һәм мөлкәти характердагы цифрлы хокуклар һәм йөкләмәләр турында Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 09 июлендәге 67 номерлы;

- «Зәй муниципаль районы Советының керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 21 июлендәге 226 номерлы;

- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар, муниципаль хезмәт вазыйфалары һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибе турында» 2018 елның 13 апрелендәге 286 номерлы;

- «Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 6 октябрендәге 411 номерлы;

- «Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Зәй муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы Нигезләмәне раслау турында» 2010 елның 2 мартындагы 359 номерлы Зәй муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 27 сентябрендәге 212 номерлы;

- «Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Зәй муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2010 елның 2 мартындагы 359 номерлы Зәй муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 2013 елның 14 июнендәге 288 номерлы;

- «Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук «Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында» Зәй муниципаль районы Советының 2010 елның 02 мартындагы 359 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 2013 елның 23 июлендәге 299 номерлы карарлары.

2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында (https://zainsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зәй муниципаль районы Советы Рәисе урынбасары П.С. Уразайкинга йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Каримов**